| СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**16 июнь 2023ел** Бишнә авылы **№142**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башлыгы И.М.Фатхуллин мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү хакында, «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Бишнә авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:
- физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның барысы да мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның барысы да мирас алудан баш тартса һәм шул 1 К вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;
- салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;
- җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Бишнә авыл җирлеге Советының 2022 елның 05 декабрендәге 108 номерлы «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә, Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**